**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең акчалата гомуми хезмәт хакы турында

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә социаль гарантияләр тәэмин итү, хезмәт хакы түләүне камилләштерү һәм аларның һөнәри хезмәт эшчәнлеген кызыксындыру максатларында, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 һәм 24 статьялары нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә (алга таба шулай ук – дәүләт хезмәткәрләре) түбәндәгеләрдән торучы гомуми хезмәт хакы билгеләргә:

дәүләт хезмәткәренең ул биләгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына туры килгән айлык окладыннан (алга таба – вазыйфаи оклад);

дәүләт хезмәткәренең аңа бирелгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте классны чинына туры килгән айлык окладыннан (алга таба – класслы чин өчен оклад);

вазыйфаи окладка дәүләт хезмәтендә тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмәләрдән;

вазыйфаи окладка дәүләт хезмәтенең аерым шартлары өчен айлык өстәмәдән;

вазыйфаи окладка дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматлар белән эшләгән өчен процентлы айлык өстәмәләрдән;

аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәр үтәгән өчен премияләрдән;

айлык акчалата бүләкләүдән;

еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүдән;

матди ярдәмнән;

махсус эш режимы, эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен айлык компенсация түләүләреннән;

вазыйфаи окладка профильле гыйльми дәрәҗә өчен айлык өстәмәдән.

2. Дәүләт хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары территориаль органнарының кече төркем вазыйфалары «тәэмин итүче белгеч» категориясе 3 разряды белгеченең 11 163 сум тәшкил иткән вазыйфаи окладына тапкырлап исәпләнә, дип билгеләргә.

3. Дәүләт хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен санаганда кулланыла торган тапкырлау коэффициентларын 1 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Дәүләт хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларына класслы чин өчен окладлар күләмен санау өчен процентлы ставкалар күләмен 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә.

Дәүләт хезмәткәренә класслы чин өчен оклад аңа класслы чин бирелгән көннән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турындагы законнар белән билгеләнгән тәртиптә билгеләнә.

5. Дәүләт хезмәткәрләренә түләргә:

1) вазыйфаи оклад һәм класслы чин өчен оклад;

2) вазыйфаи окладка дәүләт хезмәтендә тиешле еллар эшләгән өчен түбәндәге күләмнәрдә айлык өстәмә түләү:

| дәүләт хезмәте стажы | процентларда |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 10 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 15 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 20 |
| 15 елдан күбрәк | 30; |

3) вазыйфаи окладка дәүләт хезмәтенең аерым шартлары өчен айлык өстәмә:

дәүләт хезмәтенең иң югары вазыйфалары буенча – вазыйфаи окладның 12 проценты;

дәүләт хезмәтенең баш вазыйфалары буенча – вазыйфаи окладның тугыз проценты;

дәүләт хезмәтенең әйдәүче вазыйфалары буенча – вазыйфаи окладның җиде проценты;

дәүләт хезмәтенең өлкән вазыйфалары буенча – вазыйфаи окладның биш проценты;

дәүләт хезмәтенең кече вазыйфалары буенча – вазыйфаи окладның өч проценты;

4) дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматлар белән эшләгән өчен вазыйфаи окладка законнар нигезендә айлык өстәмәне;

5) аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәр үтәгән өчен максималь күләме чикләнми торган премияләр, билгеләнгән хезмәт хакы фонды чикләрендә һәм дәүләт органының бурычларын һәм функцияләрен тәэмин

итүне, вазыйфаи регламентны үтәүне исәпкә алып эшкә яллаучы вәкиле тарафыннан билгеләнгән тәртиптә;

6) вазыйфаи окладтан ике процент күләмендә ай саен акчалата бүләкләү;

7) еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү.

Еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү дәүләт хезмәткәренә ул биләгән дәүләт хезмәте вазыйфасы буенча акчалата гомуми хезмәт хакының 120 проценты күләмендә елына бер тапкыр башкарыла.

Әгәр календарь ел дәвамында дәүләт хезмәткәренә еллык түләүле отпуск бирелмәгән очракта, бер тапкыр бирелә торган түләү аңа декабрьдә эшләгән вакытына пропорциональ рәвештә, дәүләт хезмәткәре эштән киткән очракта хезмәт контракты өзелгән көннән соңга калмыйча санала һәм түләнә.

Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтендә беренче ел эшләгәндә еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү календарь елда эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә башкарыла. Эшләнгән вакыт Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтенә кергән вакыттан агымдагы календарь елның 31 декабренә кадәр исәпләнә;

8) билгеләнгән хезмәт хакы фонды кысаларында матди ярдәм;

9) вазыйфаи окладтан ике процент күләмендә аерым эш режимы өчен айлык компенсация түләүләре.

Аерым эш режимы өчен айлык компенсация түләүләре дәүләт хезмәтенең иң югары һәм төп вазыйфаларын биләгән дәүләт хезмәткәрләренә, шулай ук дәүләт хезмәтенең нормалы булмаган хезмәт көне урнаштырылган башка вазыйфаларына түләнә;

10) эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен айлык компенсация түләүләренең күләмен дәүләт хезмәткәрләре вазыйфаи окладларына карата процентлы ставкалар күләмендә 3 нче кушымта нигезендә билгеләргә. Әлеге түләү хокукый актларга һәм хокукый актларның проектларына хокукый экспертиза үткәрү, хокукый актлар проектларын әзерләү һәм редакцияләү, аларга юрист яисә югары юридик белеме булган башкаручы сыйфатында кул кую төп хезмәт вазыйфаларына кергән дәүләт хезмәткәрләренә түләнә;

11) вазыйфаи окладка айлык өстәмә:

фәннәр кандидаты профильле гыйльми дәрәҗә өчен – вазыйфаи окладтан 1,5 процент күләмендә,

фәннәр докторы профильле гыйльми дәрәҗәсе өчен – вазыйфаи окладтан ике процент күләмендә;

12) тиешле федераль законнарда һәм башка норматив хокукый актларда каралган, билгеләнгән хезмәт хакы фонды кысаларында башка түләүләр.

6. Дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт хакы фондын вазыйфаи окладлар түләүгә тотыла торган акча суммасыннан артык формалаштырганда түләү

өчен түбәндәге чаралар (елга исәпләнгән 12 вазыйфаи окладтан чыгып) күздә тотыла дип билгеләргә:

1) класслы чин өчен оклад – вазыйфаи окладларның дүрт проценты күләмендә;

2) дәүләт хезмәтендә тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмәләр – вазыйфаи окладлардан 16,5 процент күләмендә;

3) вазыйфаи окладка дәүләт хезмәтенең аерым шартлары өчен айлык өстәмә – вазыйфаи окладлардан җиде процент күләмендә;

4) вазыйфаи окладка дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматлар белән эшләгән өчен айлык процентлы өстәмәләр – вазыйфаи окладлардан 0,5 процент күләмендә;

5) аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәр үтәгән өчен премияләр – вазыйфаи окладлардан ике процент күләмендә;

6) айлык акчалата бүләкләүләр – вазыйфаи окладлардан ике процент күләмендә;

7) еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүләр һәм матди ярдәм – вазыйфаи окладлардан 10 процент күләмендә;

8) махсус эш режимы, эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен айлык компенсация түләүләреннән, вазыйфаи окладка профильле гыйльми дәрәҗә өчен айлык өстәмәләрдән – вазыйфаи окладлардан 2,5 процент күләмендә.

7. Дәүләт хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләме алар били торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары нигезендә, шулай ук айлык һәм өстәмә түләүләр күләме арттыру ягына бөтен бер сумга кадәр түгәрәкләнергә тиеш, дип билгеләргә.

8. Татарстан Республикасы дәүләт органы җитәкчесе (Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат) әлеге Указның 6 пунктында каралган түләүләр арасында дәүләт хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү фонды акчаларын яңадан бүлергә хокуклы.

9. Чит ил федератив дәүләтләре субъектларында яисә чит ил дәүләтләренең административ-территориаль берәмлекләрендә, чит ил дәүләтләрендә Татарстан Республикасы вәкилләре хезмәте өчен түләү шартлары Татарстан Республикасы Президентының аерым указы белән билгеләнә, дип билгеләргә.

10. Дәүләт сере белән даими нигездә эшләүче гражданнарга һәм дәүләт серен саклау белән шөгыльләнүче структур бүлекчәләр хезмәткәрләренә бирелә торган социаль гарантияләр күләмен билгеләү законнар нигезендә 4 нче кушымта нигезендә хезмәткә түләү фонды чикләрендә һәм мондый гарантияләрнең 2018 елның 31 мартында билгеләнгән күләменнән кимрәк булмаган күләмдә башкарыла.

11. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы бюджетында ел саен Татарстан Республикасы дәүләт органнарын тотуга бүлеп бирелүче акча чикләрендә «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм әлеге Указ нигезендә дәүләт хезмәткәрләренә акчалата гомуми хезмәт хакы түләү буенча чыгымнарны финанслауны тәэмин итүгә акча бүлүне карарга;

60 көн эчендә үз норматив хокукый актларын әлеге Указга туры китерергә.

12. Татарстан Республикасы дәүләт органнары җитәкчеләренә (Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга) дәүләт хезмәткәрләренә өстәмәләр һәм башка өстәмә түләүләр билгеләү турындагы элек чыгарылган актларны әлеге Указга туры китерергә.

13. Татарстан Республикасы Президенты указларын 4 нче кушымта нигезендә үз көчләрен югалткан дип танырга.

14. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көннән 10 көн узгач үз көченә керә һәм 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 22 март
№ ПУ-239

Татарстан Республикасы
Президентының
2018 елның «22» мартындагы
ПУ-239 номерлы Указына
5 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Президентының үз көчен югалткан указлары исемлеге**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең акчалата гомуми хезмәт хакы турында» 2006 елның 5 апрелендәге ПУ-133 номерлы Указы.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Чит ил федератив дәүләтләре субъектларында яисә чит ил дәүләтләренең административ-территориаль берәмлекләрендә, чит ил дәүләтләрендә Татарстан Республикасы вәкилләре хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2006 елның 25 декабрендәге ПУ-583 номерлы Указының 7 нче пункты.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2007 елның 3 декабрендәге ПУ-647 номерлы Указы.

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2008 елның 3 октябрендәге ПУ-490 номерлы Указы.

5. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең акчалата гомуми хезмәт хакы турында» 2006 елның 5 апрелендәге ПУ-133 номерлы Указына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 15 июлендәге ПУ-459 номерлы Указы.

6. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең акчалата гомуми хезмәт хакы турында» Указына үзгәреш кертү турында» 2011 елның 22 апрелендәге ПУ-234 номерлы Указы.

7. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 20 июнендәге ПУ-360 номерлы Указы.

8. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 13 октябрендәге ПУ-646 номерлы Указы белән расланган кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Президенты указларына кертелгән үзгәрешләр исемлегенең 2 нче пункты.

9. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 20 февралендәге ПУ-126 номерлы Указының 2 нче пункты.

10. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2012 елның 13 августындагы ПУ-646 номерлы Указы.

11. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 20 августындагы ПУ-681 номерлы Указының 2 нче пункты.

12. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең акчалата гомуми хезмәт хакы турында» Указына үзгәреш кертү турында» 2013 елның 5 августындагы ПУ-715 номерлы Указы.

13. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2013 елның 26 сентябрендәге ПУ-941 номерлы Указы.

14. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары эшчәнлеген техник тәэмин итүне тормышка ашыручы хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү системасын камилләштерү турында» 2013 елның 26 сентябрендәге ПУ-943 номерлы Указы.

15. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 23 ноябрендәге ПУ-1143 номерлы Указының 2 пункты.

16. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең акчалата гомуми хезмәт хакы турында» Указына үзгәреш кертү турында» 2014 елның 17 гыйнварындагы ПУ-34 номерлы Указы.

17. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең акчалата гомуми хезмәт хакы турында» Указына үзгәреш кертү турында» 2014 елның 7 августындагы ПУ-761 номерлы Указы.

18. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 25 мартындагы ПУ-285 номерлы Указының 2 нче пункты.

19. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын индексацияләү турында» 2017 елның 11 августындагы ПУ-668 номерлы Указы.

___